КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 июль г.Казань № 660

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1032 нче; 2017 ел, 22 февраль, 113 нче; 2018 ел, 14 май, 354 нче; 2020 ел, 24 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 31 май, 422 нче; 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба –

Тәртип) үзгәреш кертергә:

9 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) конкурс үткәрү срокларын;»;

түбәндәге эчтәлекле «$а^{1}$» пунктча өстәргә:

«$а^{1}$) заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау даталарын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

«о» пунктчасында «12» санын «14» санына алмаштырырга;

20 пунктта:

«ж» пунктчасында «максатларын,» сүзен төшереп калдырырга;

«м» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«м) субсидия алучының, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.»;

22 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Субсидия алучы Министрлыкка квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидия бирү турындагы килешүләрнең бертип формасында билгеләнгән формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешү турында хисап, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирә.»;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $27^{1}$ пункт өстәргә:

«27[1]. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү турында субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

28 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

2. Тәртипнең 8 пунктындагы өченче абзацының һәм 11 пунктындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унтугызынчы һәм егерменче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин